**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 сентябрь № 614

г. Казань

Татарстан Республикасында социаль өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны модернизацияләү һәм үстерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында кабул ителгән карар нигезендә, социаль өлкәдә эшләр һәм хезмәтләр нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү, Татарстан Республикасы халкының иҗтимагый инфраструктура объектларына ихтыяҗын канәгатьләндерү, иҗтимагый инфраструктураны үстерүгә дәүләткә карамаган сектордан акча җәлеп итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасының (алга таба – Фонд) 2016 елдан башлап Фонд тарафыннан эшләнгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү концепциясен (алга таба – Концепция) тормышка ашыруда катнашу турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органнары белән килештерелгән тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органнары белән берлектә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Фондка гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

ике ай эчендә Концепциядә күздә тотылган бурычларны тормышка ашыру өчен кирәкле чаралар турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән тәкъдимнәрне әзерләргә һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

ярты ел саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге чараларны тормышка ашыру турында хисап кертергә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда, Татарстан

Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларда катнашуга акча бүлеп бирергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары А.В.Песошинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\614.docx